**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **29 ноябрь 2021 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче Митрәй авылында 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2022 елда Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Митрәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Митрәй авылы территорияләрен төзекләндерүне оештыру (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агачларны кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Митрәй авылында бәйрәм һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне», авыл Спартакиадасында катнашучыларга бүләк һәм сувенирлар сатып алу);
- Митрәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Митрәй авылында энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү, килешү буенча эшләү өчен түләү;
- Митрәй авылы урамнарына вак таш түшәлгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, билгеләр кую, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу, киртәләр ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез, коймалар урнаштыру), чүп-чар өчен контейнерлар сатып алу) (урнашу урыны: Митрәй авылы мөселман зираты).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Митрәй авылы, Тукай ур.,15А йорт кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы Идрисов З.Ә.